

# Проект эше

Эзлән, тап, өйрән, башкаларны да өйрәт!

**Проектны эшләгәндә укучылар эшчәнлеге:**

- Төркемдә барыбыз да тигез.
- Төркемнәр ярышмый, бер- берсенә ярдәм итеп, иҗади эшли.
- Эш сезгә рәхәтлек, үз-үзеңә ышаныч хисе бирергә тиеш.
- Һәрбер укучы үз өлешен кертергә һәм бәяли белергә тиеш.
- Соңгы нәтиҗә өчен бөтенебез дә җаваплы, билге куйганда үзбәя һәм иптәшләрегез бәясе игътибарга алыначак.

# Проект эшенең формалары

- көндәлек, журнал, альбом, газета
- коллаж, комикс, сценарий
- таблица, тасвирлау, фото-, аудио-, видеоотчет
- программа, брошюра, каталог, сүзлек
- электрон презентация (Power Point)
- афиша, реклама, күргәзмә
- аннотация, рецензия, мәкалә

# Проект методының төп этаплары:

Әзерлек этабы. Проблеманы билгеләү, аның әһәмиятен нигезләү.

Эшне планлаштыру, эзләнү методларын билгеләү.

Укучыларны, шәхси теләкләрен искә алып, төркемнәргә бүлү.

Төркемнәрдә мәгълүмат җыю, аны эшкәртү, нәтиҗәләр ясау, отчет язу.

Проектларны яклау, презентацияләр ясау.

Эшкә йомгак ясау, бәя бирү.

**Кыска сроклы проект эшчәнлегенең этаплары:**

- эзләнү эше – бирелгән чыганакларны, текстны анализлау, чагыштыру;
- гамәли эш – план төзү, проект эшенең формасын сайлау, теманы ачуның алгоритмын төзү, биремнәр үтәү, белемне тикшерү өчен сораулар әзерләү;
- презентацияләү, ягъни тәкъдир итү – чыгышлар;
- уртак нәтиҗәгә килү.